СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2024 елның «26» декабре Алабуга шәһәре №403

2025 елга Алабуга муниципаль районының
милекне хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Алабуга муниципаль районы Советының 2009 елның 22 декабрендәге 257 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

**КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2025 елга Алабуга муниципаль районының милекне хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) кушымта нигезендә расларга.
2. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Җир-мөлкәт палатасы» муниципаль казна учреждениесенә 2025 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планын (программаларын) билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта басылып чыгарылырга һәм урнаштырылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов

Алабуга муниципаль районы Советының «2025 елга Алабуга муниципаль районының милекне хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында» 2024 елның 26 декабрендәге 403 номерлы карарына кушымта

## 2025 елга Алабуга муниципаль районының милекне хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы)

### 1 нче бүлек.
### Гомуми нигезләмәләр

1. 2025 елга Алабуга муниципаль районының милекне хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы) (алга таба - Фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Алабуга муниципаль районы Советының 2009 елның 22 декабрендәге 257 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы Нигезләмә нигезендә эшләнде.
2. 2025 елда Алабуга муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыруга, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын формалаштыруга юнәлдерелгән.
3. Муниципаль федераль законнарда каралган ысуллар белән хосусыйлаштырыла.

### 2 нче бүлек.
### Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

4. 2025 елда Алабуга муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез милек һәм муниципаль унитар предприятие хосусыйлаштырылырга тиеш.

5. Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган күчемсез һәм башка мөлкәт исемлеге түбәндәге таблицада китерелгән:

| № т/б | Атамасы | Урнашу урыны | Кадастр номеры | Билгеләнеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Корпус-стационар, гараж һәм җир кишәрлеге | Алабуга районы, Костенеево авылы | 16:18:130601:674<br>16:18:130601:675<br>16:18:130601:12 | Торак булмаган биналар |
| 2 | Мәктәп һәм җир кишәрлеге | Алабуга районы, Малореченский поселогы, Центральная урамы, 21 нче йорт | 16:18:140201:179<br>16:18:140201:62 | Торак булмаган бина |
| 3 | Балалар бакчасы һәм җир кишәрлеге | Алабуга районы, Илмәт ав., Нагорная урамы, 10 йнчы йорт | 16:18:090101:371<br>16:18:090101:42 | Торак булмаган бина |
| 4 | Балалар бакчасы, котельная һәм җир кишәрлеге | Алабуга районы, Яңа Мурзиха авылы, Центральная урамы, 7 нче йорт | 16:18:150101:609<br>16:18:030201:287<br>16:18:030202:7 | Торак булмаган биналар |
| 5 | Фельдшерлык-акушерлык пункты һәм җир кишәрлеге | Алабуга районы, Олы Шурняк авылы, Школьная, урамы, 8 нче йорт | 16:18:080101:285<br>16:18:080101:105 | Торак булмаган бина |
| 6 | Җир кишәрлеге һәм клуб | Алабуга районы, Олы Елово авылы, 40лет Победы урамы, 2 нче йорт | 16:18:020301:191<br>16:18:020301:308 | Торак булмаган бина |
| 7 | Төгәлләнмәгән төзелеш объекты һәм җир кишәрлеге | Алабуга районы, Костенеево авылы, Центральнаяк урамы, 25 нче йорт | 16:18:130101:665<br>16:18:130101:676 | Тоорак булмаган |
| 8 | Торак булмаган бина һәм җир кишәрлеге | Алабуга шәһәре, Малая Покровская урамы, 40 нчы йорт | 16:47:011337:64<br>16:47:011337:7 | Торак булмаган бина |
| 9 | Торак булмаган бина һәм җир кишәрлеге | Алабуга шәһәре, Мәскәү урамы, 66 нчы йорт | 16:47:011205:157<br>16:47:011205:410 | Торак булмаган бина |
| 10 | Торак булмаган бина һәм җир кишәрлеге | ТР, АМР, Алабуга шәһәре, Туйма урамы, 12 нче йорт | 16:47:011208:102<br>16:47:011208:41 | Торак булмаган бина |
| 11 | Торак булмаган биналар һәм җир кишәрлекләре | Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 82 йорт | 16:47:011202:292<br>16:47:011202:313<br>16:47:011202:345 | Торак булмаган биналар |
| 12 | Торак булмаган бина | Алабуга шәһәре, Казан урамы, 53 нче йорт, 5 фатир | 16:47:011208:213 | Торак булмаган бина |
| 13 | Республика әһәмиятендәге | Алабуга шәһәре, | 16:47:011207:165 | Торак |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | мәдәни мирас объекты булган 5 нче номерлы торак булмаган бина (реестрдагы номеры-161711058530005) | Туйма тыкрыгы, 5 нче йорт | 16:47:011207:88 | булмаган бина |
| 14 | Республика әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты булган торак булмаган бина (реестрдагы номеры-161711045110005) | Алабуга шәһәре, Мәскәү урамы, 197 нче йорт | 16:47:011336:111<br>16:47:011336:436 | Торак булмаган бина |
| 15 | Республика әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты булган торак булмаган бина (реестрдагы номеры-161711058470025) | Алабуга шәһәре, Казан урамы, 4 нче йорт | 16:47:011103:217<br>16:47:011103:267 | Торак булмаган бина |
| 16 | Республика әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты булган торак булмаган бина (контора) 161711058470015 номерлы | Алабуга шәһәре, Казан урамы, 4 нче йорт | 16:47:011103:216<br>16:47:011103:547 | Торак булмаган бина |
| 17 | Транспорт чараларын кую урыны-10 | | | Транспорт чаралары |

5. 2025 елга муниципаль мөлкәтне сатудан Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына керемнәр күләмен фаразлау 2 млн. 651 мең сум күләмендә расланган.

6. Гамәлдәге норматив хокукый актлар нигезендә, күчемсез мөлкәтне, шул исәптән аны сату бер үк вакытта шундый мөлкәтне, әлеге мөлкәт урнашкан һәм алардан файдалану өчен кирәк булган җир участокларын сатып алучыга читләштерү юлы белән гамәлгә ашырыла торган мөлкәтне хосусыйлаштыру турындагы карар, Алабуга муниципаль районы Башлыгы белән килештерелгәннән соң Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан кабул ителә.

3 нче бүлек.

Алабуга муниципаль районының мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү

7. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында мәгълүматны оператив бирү максатларында. «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе әлеге фараз планын үтәү барышында аны массакүләм мәгълүмат чараларында, муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта бастырып чыгаруны тәэмин итә.